ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРАЗАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
423750, Уразай авылы, Центральная ур., 4 йорт

СОВЕТ УРАЗАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423750, дер.Уразаево, ул. Центральная, дом 4

**КАРАР**
**21 ноябрь 2019г.**

**РЕШЕНИЕ**
**№33**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25,1,56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 7 августындагы 45-ТРЗ номерлы татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Уразай авыл җирлеге гражданнары җыены

Карары:

1. Уразай авыл җирлеге территориясендә 2020 нче елда, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары, көндезге формада белем алучы студентлар, 1 төркем,балачактан инвалидлардан кала, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләүләр кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә.:

**Юл эшчәнлеге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата:**

-юлларны ремонтлау һәм карап тоту (ПГС һәм ЩПС салу, грейдлау, кардан чистарту)

**Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту:**

- зират территориясендә агач кисү;

-ритуаль хезмәтләр өчен инвентарь сатып алу;

- зират коймасын ремонтлау;

**Җирлек халкының массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру һәм халык күпләп ял итә торган урыннарны төзекләндерү:**

- рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын оештыру һәм уздыру;

**Җирлек чикләрендә Халыкны электр, җылылык, газ һәм су белән тәэмин итү, су чыгару, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру:**

-торак пунктларда су челтәрләрен ремонтлау, карап тоту, су чыганакларын ремонтлау һәм лицензияләү;;

**Җирлек территориясен төзекләндерү һәм яшелләндерү эшен оештыру:**

- авыл җирлеге территориясендә агач кисү;

- Сабантуй үткәрү урыннарын төзекләндерү;

- җирлек торак пунктларында хуҗасыз территорияләрне ремонтлау һәм киртәләү.;

**Торак пунктларда гражданнарның яшәү урамнары, мәйданнары һәм башка территорияләре исемнәрен бирү, йортлар нумерациясе урнаштыру, урамнарны яктыртуны оештыру, урам исемнәре һәм йорт номерлары булган күрсәткечләр урнаштыру:**

- урам исемнәре һәм йорт номерлары белән күрсәткечләр урнаштыру ; ;

- урамнарны яктырту электр челтәрләрен карап тоту;

**Җирлек милкендә булган мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне) саклау, куллану һәм популярлаштыру, җирлек территориясендә урнашкан җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне) саклау:**

- һәйкәлне ремонтлау һәм реконструкцияләү;

**муниципаль җирлек милкендә булган мөлкәтнең biләве, аннан файдалану һәм алар белән эш итү:**

декларация алдыннан ГТСНЫ тикшерү.

2. Актаныш муниципаль районы Уразай авыл җирлеге гражданнарының авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында җыелу нәтиҗәләрен игълан итәргә.

3. Актаныш муниципаль районы Уразай авыл җирлеге гражданнарының җыены нәтиҗәсен Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында "авыл җирлеге"бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

Уразай авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Шарипов